Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№ 39 (90)

5 декабрь 2013 ел

## Вакыйгалар эзеннән

**30 НОЯБРЬДӘ** «Спорт сөюче Казан – 2013» спартакиадасының II этабы кысаларында Бокс һәм өстәл теннисы үзәгендә **ӨСТӘЛ ТЕННИСЫ БУЕНЧА ЯРЫШЛАР УЗДЫРЫЛДЫ**. А.Шпагонова (юридик факультет ассистенты), А.Иванов (А.М.Бутлеров ис. Химия институтының өлкән фәнни хезмәткәре), А.Садыйкова (гомумуниверситет физик тәрбия һәм спорт кафедрасының өлкән укытучысы) составындагы КФУ укытучылары һәм хезмәткәрләренең җыелма командасы белем бирү учреждениеләре командалары арасында беренче урынны яулады. Җиңүчеләрне котлыйбыз!

• • • •

**1 ДЕКАБРЬДӘ** «Уникс»та **КФУ**ның **АЧЫК ИШЕКЛӘР КӨНЕ УЗДЫ**. Якшәмбе көнне иртәдән үк бирегә мәктәп укучылары, аларның әти-әниләре агылды. Укырга керү турындагы мәгълүматны белергә теләүчеләр бик күп иде. «Уникс»ка барлыгы 1200дән артык кеше җыелды.

• • • •

**2 ДЕКАБРЬДӘ** Казан федераль университеты **РЕКТОРАТЫНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ** булып **УЗДЫ**. Аны, гадәттәгечә, ректор **ИЛШАТ ГАФУРОВ** җитәкләде. Икътисад һәм стратегик үсеш буенча проректор **М.САФИУЛЛИН** КФУның структур бүлекчәләре рейтингы турында сөйләде һәм премияләү фондын формалаштыру мәсьәләсе буенча тәкъдимнәрен җиткерде. Проректор шулай ук 2013-2020 елга КФУның дөньядагы иң алдынгы фәнни-мәгариф үзәкләре арасында конкурентлык сәләтен арттыру һәм Үсеш программаларын тормышка ашыру мәсьәләсе буенча да хисап тотты. 2014-2015 уку елында КФУга чит ил студентларын кабул итү хакында тышкы бәйләнешләр буенча проректор **Л.ЛАТЫЙПОВ** сөйләде. Хәзерге көндә университетта 798 чит ил студенты белем алса, 2020 елга аларның саны 3336га җитәргә тиеш. Бу уңайдан, университетка чит ил студентларын җәлеп итү максатында, рекрутинг агентлыклары белән эшләү, күргәзмә чараларында катнашу, Росхезмәттәшлек белән элемтә урнаштыру планга кертелгән. Аннан соң ректорат психология һәм белем бирү институтында ярдәмчел структур бүлекчә – «Мәгариф һәм үзлектән үсеш» дип аталган яңа журнал редакциясен оештыру, хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институтында сан анализы лабораториясен ачу өчен тавыш бирде.

• • • •

**3 ДЕКАБРЬ** көнне, илнең барлык хокукчыларының һөнәри бәйрәмнәре – Юрист көнендә, Мәскәүдә **«ЕЛ ЮРИСТЫ» ПРЕМИЯСЕН ТАПШЫРУ ТАНТАНАСЫ УЗДЫ**. Әлеге бүләкне инде бишенче ел рәттән Россиянең юристлар ассоциациясе тапшыра. Быел әлеге дәрәҗәле премиягә юридик факультет деканы Илдар Тарханов та лаек булды. Илдар Габделхаковичны чын күңелдән котлыйбыз!

• • • •

КФУ профессоры, биология фәннәре докторы **Н.МИНҺАҖЕВА** 2 декабрьдә Мәскәүдә башланып киткән әйләнә-тирә мохитне саклау буенча **ДҮРТЕНЧЕ БӨТЕНРОССИЯ СЪЕЗДЫНДА КАТНАША**. Бу Россиядә игълан ителгән Әйләнә-тирә мөхитне саклау елы уңаеннан үткәрелә торган иң масштаблы чара булып тора.

• • • •

Шушы көннәрдә Казан университеты укытучылары, студентлары һәм лицеистлары бөек галим, математик **Н.ЛОБАЧЕВСКИЙНЫ ИСКӘ АЛДЫЛАР**, аның **ҺӘЙКӘЛЕНӘ ЧӘЧӘКЛӘР КУЙДЫЛАР**. Быел аның тууына 221 ел тулды. Җыелучылар арасында Идел буе математика олимпиадасына килүчеләр дә бар иде.

• • • •

**КФУ**ның **ИКЪТИСАД ҺӘМ ФИНАНСЛАР ИНСТИТУТЫ СТУДЕНТЛАРЫ** ноябрь ахырында Новосибирскида үткәрелгән салым һәм салым салу өлкәсе буенча **ТӨБӘКАРА ОЛИМПИАДАНЫҢ КӨМЕШ ПРИЗЕРЛАРЫ ДӘРӘҖӘСЕНӘ ИРЕШТЕЛӘР**. Конкурста Россиянең 9 төбәгеннән 200ләп студент катнашты. Казан университеты данын салым һәм хокук кафедрасы магистрлары Р.Әгъләмова, Ю.Воронова, А.Заяц, Г.Нуруллова, Д.Юлдашева яклады. Җиңүчеләрне тәбриклибез!

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*



Влад Михневский фотосы

# Университетта «яшибез»!

Уку йортыбызның юридик факультетында тормыш гел гөрләп тора. Бу аларның төп бинада урнашуларына һич тә бәйле түгел. Юристлар көне уңаеннан, сезне алар белән якынрак таныштырырга телибез. Бүген «Безнең тышлык»та – бу структур бүлекчәнең фәнни эшчәнлек буенча активистлары – студентлар фәнни җәмгыятенең халыкара конференцияләр, түгәрәк өстәлләр һәм телекүперләр буенча рәис урынбасары, III курс студенты Динар Вәлиев һәм шул ук җәмгыятьнең фәнни эшчәнлек буенча рәис урынбасары, V курс студенты Татия Бахия. *Дәвамы 2 биттә.*

• Безнең тышлык

# Университетта «яшибез»!

**Алинә САДЫЙКОВА**

**Башы 1нче биттә.**

Аларның университет тормышы һәр елны кимендә өч-дүрт зур масштаблы чарадан тора. Берсен үткәреп җибәрүгә, икенчесенә әзерләнә башлыйлар. «Күптән түгел генә бездә халыкара конференция булды. Без аны хөрмәтле профессорыбыз М.Челышев истәлегенә багышлап уздырдык. Анда Россиянең төрле почмакларыннан һәм якын чит илләрдән 400ләп студент катнашты», – диде Татия. Хәзер инде алар икенче проект – «Бөтенроссия суд дебатлары»на әзерләнә. Студентлар үзләренсудта дип хис итәләр һәм алдан әзерләгән материаллары буенча чыгыш ясыйлар. Аларның чыгышларын читтән чакырылган профессиональ казыйлар, прокурор һәм юристлар бәяли. Өч турдан торган бәйге азагында иң көчле команда билгеләнә һәм бүләкләнә.



Шушы өч-дүрт чара белән чикләнеп кала икән болар, дип уйлый күрмәгез, Динар һәм Татия катнашында оештырылган конференцияләрнең иге-чиге юк һәм аларның күбесе федераль яисә төбәк дәрәҗәсендә уздырыла. «Зур көч куеп әзерләгән чараңның югары дәрәҗәдә үтүе һәм аның өчен остазларыңнан, иптәшләреңнән рәхмәт сүзе ишетүдән дә рәхәт әйбер юктыр!», – дип, хисләре белән уртаклашты яшьләр. Мисал өчен, Луис М.Браун исемендәге хокук буенча консультацияләр бәйгесе Россия кысаларыннан да чыгып китә икән. Бу чара иң беренче Стамбулда уздырылган, хәзер исә ул Казан университеты базасында оештырыла. Ике этаплы бәйгенең беренче өлеше КФУда үтсә, икенчесе башка илдә уза. Илләр ел саен алышынып тора. Үткән елларда икенче турга узган студентлар Һиндстанга, Япония, Мадагаскарга кадәр барганнар.

Конференция була да узып китә, аннары рәхәтләнеп ял итәләр, дип уйларсыз. Юк, ялгышасыз! Факультет кысаларында һәрдаим фәнни түгәрәкләр эшли. Аларның саны инде егерме дүрткә җиткән. Күбесе студентларга кызык булган дисциплиналар буенча чыгып оештырыла. Мәсәлән, монда җинаять, гражданлык, гаилә, спорт хокукы һ.б. түгәрәкләр актив рәвештә үзләренә студентларны җәлеп итәләр. Биредә студентлар төрле конференцияләргә әзерләнә, тәҗрибә уртаклаша. «Темалар эзләгәндә, каршылыклы фикерләр тудыра торганнарын сайларга, чыгышларны төрле позицияле итеп әзерләргә тырышабыз. Андый очракта көтелмәгән дискуссияләр туа һәм кызыклы нәтиҗәләр ясала», – диде Динар. Күренеп тора: ул мәсьәләләрне җиңел юллар белән генә хәл итәргә яратмый, ә төптән уйлап эш итә.

Бу очрашулар бер аудиториягә җыелып сөйләшеп утыруга гына кайтып калмый. Мисал өчен, «Җинаять хокукы» түгәрәгенә йөрүчеләр колонияләргә баралар икән. Әле күптән түгел генә хатын-кызлар өчен һәм катгый режимлы колонияләрдә булып кайтканнар. «Мондый чаралар безне шул мохиткә алып керә, аны эчтән күзәтергә мөмкинлек бирә. Бу безнең өчен практик яктан бик мөһим», – дип белдерде Татия.

Спорт хокукы чагыштырмача яңа тармак булып санала һәм аның буенча махсус эшкәртмәләр әлегә юк дәрәҗәсендә. Әйтик, бер утырышта студентлар сөйләшү темасы итеп футболны юкка гына сайламаганнар. Алар бу спорт төренә мөкиббән икән. Факультет эчендә һәр курс, командаларга берләшеп, инде өч ел рәттән турнирлар үткәрәләр. Бу чараны җинаять хокукы кафедрасы оештыра. Нәтиҗәдә, җиңгән команда әлеге кафедра укытучылары белән көч сынаша. Быел остазлар дүртенче курслар белән уйнап, җиңүгә ирешкән. Гаҗәп тә түгел, ул кафедрада профессиональ футболчылар эшли икән.

Әлбәттә, бу дәрәҗәдә актив студентлар башка өлкәләрдә дә зур үрләр яулый. Алар укуда да алдынгылар рәтендә.

Сүз уңаеннан, активистлар 12 декабрь көнне юридик факультетның туган көнен зурлап үткәрергә җыеналар. Бер булганнан бар да була: бу бәйрәмнең программасын да тулысы белән студентлар әзерләячәк.

Бу кадәр күләмле эшне башкарырга өлгерергә дә кирәк бит әле! «Кайчакта университет каравылчылары безне бинадан кичке 11дән соң да куып чыгаралар! Монда төнгә калу идеясе дә бар иде – тик рөхсәт итмиләр», – дип көлешеп куйды яшьләр.



**3 декабрьдә Россиядә Юрист көнен билгеләп үтәләр.** Бәйрәмне гамәлгә кертү указына 2008 елның 4 февралендә РФ Президенты В.Путин кул куя.

**Россиядә юриспруденция фән буларак XVIII гасырда танылa.** Бу вакытка кадәр ул, гомумән, гамәли характерда гына була. Петр I патшалык иткән заманнарда юристлар хокукның теоретик ягын түгел, ә күбрәк аны системалаштыру, тулыландыру, җитешсезлекләрне киметү, бер-берсенә каршы килгән актларны тәртипкә салу белән шөгыльләнгәннәр.

**1725 елда Петр I әмере белән төзелгән Петербург Фәннәр Академиясендә Россиянең беренче хокукчы-галимнәре белем ала башлый.** Баштарак юридик фәннәрне патша чакырткан немец галимнәре укытса, инде XVIII гасыр урталарыннан бу эшкә рус профессиональ юристлары алына.

**1802 елның 8 сентябрендә Россиядә юстиция министрлыгы оеша.**

Илебез юриспруденциясен яңа һәм югары дәрәҗәгә чыгарырга ике вакыйга ярдәм итә: тулы законнар җыелмасы белән Россия Империясенең законнар җыентыгын бастыру һәм 1864 елгы суд реформасын кабул итү. Бу вакыт эчендә юриспруденция фәненә ныклы нигез салырга сәләтле юристлар төркеме формалаша. Алар рус юриспруденциясенең нигезе итеп герман юриспруденциясен сайлыйлар.

**Хәзерге вакытта Россиядә юристлар һәм аларның ассоциацияләренең берничә федераль һәм дистәләгән төбәк һәм коммерцияле булмаган корпоратив оешмалары бар.**

Бәйрәм датасын сайлаганда, берничә вариант тәкъдим ителгән булган. Ни өчен нәкъ менә 3 декабрь көне сайланган соң? 1864 елда бу көнне суд реформасы нигезенә яткан суд уставлары сериясе һәм башка закон чыгара торган актлар кабул ителгән. Шуларга өстәп, 1917 елга кадәр бу көнне Россия хокукчылары үзләренең һөнәри бәйрәмнәре дип исәпләгәннәр.

• Сәләткә сәбәп кирәк

«Vous etes tres belle chanter!» Ни әйткәнемне аңламадыңмы? Бу француз телендә «Сез бик матур җырлыйсыз!» дигән сүз. 4 декабрь көнне «Уникс» концертлар залында узган «Француз теле һәм мәдәнияте» фестивалендәге һәр катнашучыга шулай диясем килде. Гомумән, бу телгә гашыйк булдым.

# Җырлар аша Франциягә

Әлеге фестиваль 1989 елдан башлап, Казан университетында француз телен өйрәнүгә ярдәм йөзеннән уздырыла.

Быел, фестивальгә 25 ел тулу уңаеннан, аны конкурс форматында түгел, ә концерт итеп оештырдылар. Кичәнең сценарий авторы - хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты студенты Лилия Әхмәтҗанова: «Без бу чарада француз телен ни дәрәҗәдә яратуыбызны, өйрәнергә теләвебезне күрсәтәбез. Монда уку йортыбызның төрле факультетларыннан беренче - дүртенче курс студентлары катнаша. Алар французча җырлыйлар, шигырьләр сөйлиләр, кыскасы, бөтен талантларын күрсәтәләр», - дип, фикерләре белән уртаклашты. Инженерия институтының 2 курс студенты Регина Сәлимуллина инглизчә җырларга ярата икән. Бу юлы ул үзен француз телендә җырлап сынап карарга уйлаган. «Бу телне белмим, шуңа күрә җырны иҗекләп өйрәндем», - диде һәм үзенең моңлы тавышы белән таң калдырды. «Destiny-p» рэп-төркеме үзләре язган җырны башкарды. Тамашачы әлеге чыгышны көчле алкышларга күмде.



Тел институтының француз теле кафедрасы җитәкчесе, филология фәннәре докторы, профессор, академик Пальмалар Кавалеры (Франция), сәнгать һәм әдәбият өлкәсе Кавалеры (Франция), ТРның Мактаулы мәдәният хезмәткәре, Педагогика фәннәренең Халыкара Академиясе академигы **Элмира Хәбибуллина**: «Быел килгән беренче курслар бик актив, тизрәк сәхнәдә чыгыш ясыйсылары, талантларын күрсәтәселәре килә. Шуңа күрә концерт оештырдык. Ә иң-иңнәрне зур бүләк көтә: алар Франциягә барачак һәм Авиньонның зур сәхнәсендә чыгыш ясаячаклар», – диде.



Влад Михневский фотолары

• Белем буразналары

# «Күчмә» чыганаклар



**Дания ФАТЫЙХОВА**

Шушы араларда Звенигород шәһәрендә урнашкан Россия фәннәр академиясе пансионатында «Урта гасыр Евразия күчмә халыкларының тарихы буенча чыганаклар» исемле VII Халыкара симпозиум булды.

Форумны Россия фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты һәм Венгр фәннәр академиясе оештыртырды. Анда Россия Федерациясе, Венгрия, Болгария һәм Монголиядән күчмә халыклар цивилизациясен өйрәнә торган танылган галимнәр катнашты. Татарстан фән эшлекләләре делегациясе составында КФУның Халыкара бәйләнешләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты профессоры А.Борһанов та бар иде.

Конференция кысаларында сигез пленар утырыш узды. Анда язма чыганаклар һәм историография, археологик һәйкәлләр, нумизматика һәм эпиграфика, текстология һәм фольклор, борынгы кораллар һәм декоратив-гамәли мәдәният, рухи мәдәният тарихы буенча чыганаклар мәсьәләләренә багышланган 33 доклад белән чыгыш ясадылар. А.Борһанов «Күчмә халыкларның Урта Амударья ярларында яшәп, җир эшкәртү белән шөгыльләнгән халыкларның мәдәниятенә тәэсире» темасы белән чыгыш ясады һәм бу турыда кызыклы мәгълүматлар җиткерде.

Конференция барышында Россия һәм чит илләрдән килгән галимнәр арасында ныклы фәнни элемтәләр булдырылды. Симпозиум нәтиҗәсе итеп, оештыру комитеты фәнни мәкаләләр җыентыгы чыгарырга ниятли.

• Калеб

# «Әйе, бар ул кабатланмас сүзләр...»



Хәзер Анна Ахматова иҗатын татарча укырга да мөмкин. Шушы көннәрдә аның шигырьләренең татар теленә тәрҗемә ителеп басылган китабын тәкъдир ителде.

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының Кече сәхнәсендә узган кичә танылган рус шагыйрәсенең иҗатын татарча яңгыратуга гына түгел, аны мөмкин кадәр тулы итеп ачуга да юнәлдерелгән иде. Кичәдә без Ахматованың аталы шигырьләрен тәрҗемәдә генә ишетеп калмадык, ә шагыйрә дөньясына үтеп кереп, аның белән бергә XX йөзнең хәлиткеч вакыйгаларында да катнаштык.

Кемнендер исәпләүләре буенча, Анна Ахматова үз гомерендә 78 телгә 150 шагыйрьне тәрҗемә иткән. Алар арасында Габдулла Тукай әсәрләре дә бар икән. Ләкин А.Ахматова үз шигырьләрен тәрҗемә итәргә яратмаган. Шуңа да карамастан, шагыйрәнең иҗаты күп телләргә тәрҗемә ителгән һәм ителәчәк. Аның шигырьләрен хәтта кытай һәм корея телләрендә дә укып була. Хәзер инде без аны туган телебездә дә укый алабыз.

Китап Анна Ахматованың 120 еллык юбилеена багышлап әзерләнгән. М.Вәлиев җитәкләгән «Мәгариф-вакыт» нәшриятында дөнья күргән китапның идея авторы һәм төзүчесе – Л.Хафизова. Әдәби мөхәррире – Р.Аймәт. Шулай ук ул кайбер шигырьләрне дә тәрҗемә иткән. Тәрҗемәче-шагыйрьләр: Илсөяр Иксанова, Йолдыз Миңнуллина, Рифә Рахман, Луиза Янсуар, Лилия Гыйбадуллина, Гөлназ Вәлиева – Ахматова иҗатын халыкка, нигездә, үзләре тәкъдим итте.

Китап шактый четерекле, урау юллар үткән һәм аңа быел, ниһаять, дөнья күрү насыйп булды. Күп еллар дәвамында Советлар Берлегендә шигырьләрен бастыру түгел, хәтта кәгазь битенә төшерергә дә шөбһәләнеп яшәгән шагыйрәнең язмыш фалы кабатланды гүя. Әмма китап, күпләрнең тырышлыгы белән, барыбер үзенә юл ярды. Кичәгә килгән тамашачы аның ничек тәрҗемә ителүе, басылуы, бизәлүе хакында җентеклəбрәк белде, аннан соң китапны фойеда сатып алып та китә алды.

Җыентыкта Ахматова лирикасының иң яхшы үрнәкләре генә тупланып калмаган, ә күпмедер дәрәҗәдә заманча татар поэзиясенә ниндидер яңа контекст эзләү дә сизелә кебек.

Гомере буена классик музыка сәнгатенә мөккибән булган Анна Андреевнаның иң яраткан композиторлары иҗаты да яңгырады. Кичәгә, әйтерсең, шагыйрь үзе килде! Пианист, Казан дәүләт консерваториясе мөгаллиме Дарья Сосновская тәкъдим итеелешендә... Музыкантның затлылыгы, үз-үзенә «бикләнә» белүе, хәтта тышкы кыяфәте дә Ахматованы хәтерләтте (*фотода*).



Элнар Байназаров фотосы

## *Төнлә*

**Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА**
тәрҗемәсе

*Вак болытлар арасында тора*
*Ярым тере төнге ай гына.*
*Каш җыерып карый усал сакчы*
*Манарага, сәгать ягына.*

*Кайтып килә хыянәтче хатын,*
*Кырыс, уйчан аның карашы.*
*Ә тугрысын, утлы хафа булып,*
*Төн йокысы буа башлады.*

*Миңа нәрсә? Җиде тәүлек элек*
*Хуш дидем мин фани бу җиргә.*
*Бөрку анда. Мин бакчага чыктым*
*Төнге йолдызларны күрергә.*

*1918 ел*

• Премьера

# Курчаклар юл кагыйдәләрен аңлата

**Ләйсән ИСХАКОВА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

3 декабрь көнне Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачылар театрында Татарстанның атказанган артисты Илфат Камалиев куелышында «Супер-светофор» (Аманулла әсәре буенча) балалар спектакленең премьерасы булды.



«Супер-светофор» – «Светофорда кунакта» спектакленең яңартылган варианты. Яңа куелышта төп герой, Светофор Светофорович, үзенең тылсымлы таягы ярдәмендә мәктәп укучылары Айдар белән Аленаны үткәнгә – балачакларына кайтара. Ул чакта алар Юл йөрү кагыйдәләрен бозучылар рәтендә булганнар. Кагыйдәләрнең ни рәвешле бозылганлыгын балаларга курчаклар җентекләп аңлата. Мондый үзенчәлекле алымны Яшь тамашачылар театрында әле тәүге мәртәбә генә файдаланалар. Шуңа берникадәр авырлыкларга да юлыкканнар. Әмма балалар юл йөрү кагыйдәләрен яхшырак истә калдырсын өчен, тамашага курчаклар белән уенны кертеп җибәрү үз нәтиҗәсен бирер, дигән өметләр зурдан.

Мондый спектакль кую турындагы фикерне ТР буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе башлыгы Рифкать Миңнеханов әйткән. Дөресрәге, ул «Светофорда кунакта» спектаклен яңартырга тәкъдим иткән. Бу уңайдан, Г. Кариев театрының ТР ЮХИДИ идарәсе белән хезмәттәшлек итүе хакында да әйтеп китәргә кирәк.

«Супер-светофор» балалар бакчаларында һәм мәктәпләрдә дә рус һәм татар телләрендә куелачак. Спектакль барышында актерлар кечкенә тамашачылар белән иркенләп аралаша. Балалар исә актерларның Юл йөрү кагыйдәләренә караган сорауларына җавап бирү, ә рус телендә аралашучы нәни тамашачылар татар телендәге сүзләрне кабатлау мөмкинлегенә ия.

Актерларның өч составы булдырылган. Спектакльне берьюлы берничә мәктәптә күрсәтү мөмкинлеге булсын өчен, курчакларның да ике составы әзерләнгән.

«Супер-светофор»ны Казанда гына түгел, башка шәһәрләрнең театр сәхнәләрендә дә күреп булачак. Якын киләчәктә гастрольләр Ульяндa узар, дип көтелә.

• Бәйге



Аидә Әгълиуллина фотосы

# Кечкенә якты йолдызлар

Филология һәм мәдиниятара багланышлар институтында быел беренче тапкыр үткәрелгән «Мин – алып баручы!» студентлар конкурсы төгәлләнде. Үзен төрле чараларда рус һәм татар телләрендә алып баручы буларак сынарга теләгән 30 кандидаттан финалга бары 10 конкурсант чыкты.

**Элвира НОВИКОВА,**
«ТРның Студентлар Лигасы» матбугат үзәге

Кемнең генә, сәхнәгә чыгып, якты утлар астында чын йолдыз булырга хыялланганы юк икән? Кызганыч, кем өчендер бу хыял булып кына кала, ә кемдер, максатына ирешү өчен, кулдан килгәннең барысын да эшли. ФһМБИ, үз студентларының хыялларын тормышка ашыру, алар арасыннан иң иҗади, иң креатив һәм иң яхшы алып баручыларны сайлап алу максатыннан, «Мин – алып баручы!» конкурсын оештырды.

Финалистлар үзләренең «Визит карточкасы»н, «Өй эше»н һәм иҗади номерын тәкъдим итте. Конкурсантлар һәр биремгә җитди әзерләнгән: «Өй эше» бәйгесендә студентлар үзләрен «Пусть говорят», «Танцы со звездами», «Интуиция» кебек популяр телепрограммаларның алып баручылары ролендә сынап карады. Алар, шулай ук, нинди дә булса концертны алып барган вакытта килеп чыккан төрле очраклардан чыгу юлын табарга тиеш иде. Мәсәлән, Кыш Бабай белән Кар Кызын ничек үзенчәлекле итеп чакырырга яисә сәхнәдә Сергей Лазарев түгел, ә Филипп Киркоров икәнен тамашачыга ничек итеп аңлатырга һ.б. кызыклы очраклар бар иде.

Финалистларның тырышлыклары һәм осталыкларын мәртәбәле жюри бәяләде. Конкурсның җиңүчеләре дип Алинә Хәйруллина (2 курс) һәм Илназ Сибгатуллин (2 курс) табылды. 2 урынга Камилә Татлыева (3 курс), Булат Алеев (3 курс), Элвина Нәҗипова (3 курс), 3 урынга Айзилә Батрханова лаек булды.

«Мин – алып баручы!» конкурсы ФһМБИда беренче тапкыр үткәрелсә дә, ул югары дәрәҗәдә узды. Оештыручылар алдагы елларда бәйгене тагын да камилләштерергә уйлыйлар. Беренче бәйге бары тик шушы институт студентлары арасында гына үткәрелсә, киләчәктә бәлки монда үзләренең талантларын башка институт-факультет студентлары да күрсәтә алыр. Шуңа күрә хәзердән үк дикцияне яхшыртырга һәм тизәйткечләрне өйрәнә башларга кирәк!

● Әдәби сәйләнләр



Мин, Абдрахманова Айгөл Айрат кызы, 1993нче елның, 4 августында Кайбыч районының гүзәл табигатьле Борындык авылында дөньяга килгәнмен. Хәзерге вакытта КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында укыйм.

Кечкенәдән иҗатка гашыйк булдым. Әнием сүзләренә карагында, 6 яшемдә дәренче тамагымны язганмын. Баштагы мәлдә шигырьләр язу белән мавыксам, 11 сыйныфтан хикәяләр яза башладым. Бүгенге көндә «Әллүки» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы, иҗатымны үстерү, камилләштерү өстендә эшлим. Сезнең игътибарга бер хикәямне тәкъдим итәм.

# Җил һәм Суык яки аңлашу

Гадәттә, Җилнең көне бик күңелле уза. Иртә таңнан, йорт тәрәзәләрен кагып, кешеләрне йокыдан уята. Аннан соң укырга баручы балалар белән шаяра: я баш киемнәрен алып очыра, я төймәләнмәгән пәлтә итәкләрен ачып уйный. Кайбер көннәрдә, йокы симертеп, укырга барырга соңга калган малайларны, артларыннан этеп-төртеп, мәктәпкә илтеп куя. Төштән соң кечкенә балалар белән куыш, качыш, кар атыш уйный. Ә кичен, караңгы төшкәч, урамда ялгызы гына калган кечек белән серләшеп утыра Җил. Бүген гадәти көн түгел шул. Бүген – якшәмбе, житмәсә, Суык та килде. Урамда бөтенләй бер кеше дә юк.

– Ну шул Суыкны. Мөмкинлек булган саен, миңа комачаулый, – дип, Җил чын күңеленнән үзенең дустына үпкәләде.

Төштән соң, Җил тынды, дөресрәге, Суыктан качып, клуб бакчасында үсеп утырган каен төбенә барып утырды. Суык та, үпкәләп, әллә кая югалды. Авыл бөтенләй «үлде».

Күңелсезлеге белән аерылып торган бу көнне бернәрсә дә үзгәртә алмас иде кебек. Ләкин ап-ак карга төренгән агачлар арасыннан килеп чыккан бер кеше Җилнең кәефен күтәреп җибәрде. Җил аны ерактан ук танып алды. Дөресен генә әйткәндә, ак башлык кигән, кара тунын пута белән кысып бәйләгән, озын толымнарын иек аска чыгарып салган бу сылу затны танымау мөмкин түгел иде. «Айсылу ич бу», – диган уйдан Җилнең күңелен шатлык биләп алды. Ләкин кызның тездән карга батканлыгын, бит урталарының кызарып-пешеп чыкканлыгын күргәч, илаһи зур шатлык «ә» дигәнче юкка чыкты. «Тагын Суык белән уйнаган, тагын аны миннән өстенрәк күргән», – дип ачуланды Җил. Ул үзенең ризасызлыгын Айсылуга күрсәтергә булды һәм, бар көчкә чабып барып, кызның толымнарын артка алып атты, битен чеметте, башлыгын салдырырга тырышты.

– Әй, Җил дустым, ни булды сиңа бүген? Нигә шулай дулыйсың?

– Нигә?! Әле тагын сораган булып тора бит! Мин тәрәзә шакып чакыргач та чыкмадың, ә Суык белән битләрең кызарганчы уйнагансың.

– Суык ул теләсән-теләмәсәң дә битне кызарта. Ә урамга мин уйнарга дип түгел, бер кеше белән күрешергә дип чыктым.

– Айсылу, Айсылу, ә нинди кеше ул? Ә нинди очрашу ул? Бер-бер хәл булмагандыр бит? – дип, Җил, кечкенә баладай, кызга сораулар яудыра башлады.

– Бернәрсә дә булмады, әнинди кеше икәнлеген белү сиңа кирәк түгел, – дип ачулана башлады Айсылу.

– Сөйлә инде, дип ялынды аңа дусты.

– Сиңа сер сөйләргә ярамый бит, барысын да чәчеп-таратып бетерәчәксең.

Җил бер сүз дә дәшмәде. Нәрсә дип әйтсен соң ул? Айсылу дөрес сөйли бит. Дуслар арасында үле тынлык урнашты. Җил үзенең шундый булып туганына үкенде.

– Кирәк бит ә, мин хәтта сер дә саклый белмим! Мин беркемгә дә кирәкмим! Мине беркем дә яратмый!

Үзәк өзгеч шушы сүзләрдән әйләнә-тирәдәгеләрнең күңел кыллары тибрәнде. Ап-ак кардан шәл ябынган агачлар, авыр сулап, уфтанып куйдылар. Айсылу да түзмәде:

–Җил, гафу ит, зинһар өчен! Мин сине үпкәләтергә теләмәдем, – дип кычкырып җибәрде. – Гафу ит инде, кил яныма. Сөйлим, барысын да сөйлим мин сиңа.

Җил, ялындырып кына, Айсылу янына елышты.

– Мин кая барганымны беркемгә дә, хәтта әнигә дә әйтмәдем. Син тәрәзә шакыганда, уйнарга түгел, йомышым булса да, чыгарга исәбемдә юк иде.

– Ә нигә чыктың соң, исәбеңдә булмагач?

– Айнур – минем сыйныфташым – шалтыратты да клуб бакчасына килүемне үтенде. «Бик мөһим темага сөйләшәсе бар», – диде

–Соң, Айсылу, син кичә генә але аның белән ачуланыштың түгелме соң? Бар урамга яңгыратып әрләштегез дә, икегез ике якка борылып кайтып киттегез ич. Әллә дуслашмакчы буламы икән, бәлки гафу үтенергә телидер,ә?

– Белмим, белмим инде, дустым. Аның ише кеше гафу үтенсә, кояш икенче яктан чыгачак... Балалар бакчасыннан бирле бергә уйнап үстек, бер үк елны мәктәпкә укырга кердек, алтынчы сыйныфка кадәр бер парта артында утырдык. Без аның белән утны да, суны да бергә кичтек дияргә була, ә ул... Ә ул, нәкъ менә унберенче сыйныфка җиткәч, мине үзенең дошманына әйләндереп куйды. Минем һәрбер хәрәкәтем, һәрбер әйткән сүзем Айнурның ачуын чыгара бугай. Үзенә ярарга тырышуымны аңламыймы икән әллә ул? Мин аңа, елмаеп, бәрәр сүз әйтсәм, җүләр кешегә караган кебек карый. Менә кичә актык дәрестә, мине кеше көлкесенә калдырып, шигырь язган:

*«Классташым Айсылу атлы.*
*Акыллы ул, теле татлы.*
*Чибәр ул Зөһрә кыздай,*
*Аннан көнләшәдер ай».*

Шуңа күрә ачуланыштык та инде без.

– Айсылу, синнән көлеп язмаган ич ул бу шигырьне, үзенең хисләрен белдерергә теләгән бит.

– Син дә ачуымны китереп торма әле, – диде Айсылу. Ул үзенчә ачуланырга тырышты, ләкин иреннәре ирексездән елмайды, оялуыннан бит урталары кызарып чыкты, кыз күзләрен кая яшерергә белмәде. Әйләнә-тирәдәгеләр аның хисләре – гашыйк булуы турында беләдер кебек тоелды.

Ләкин тирә-юньдә агачлар һәм дусты Җилдән тыш беркем дә юк иде. Агачлар ап-ак юрган ябынып йоклыйлар, ә Җил исә, гомердә булмаганны, тирән уйга баткан иде. «Шушы уналты-унҗиде яшьлек кызлар-егетләр дә мәхәббәт дигән нәрсәне беләме икән? Аларга да бу бөек хис таныш микән әллә?»

***Дәвамы икенче санда.***

● Халәт

# Планлаштырылмаган бәйрәм

**Илүсә АРИКЕЕВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Тулай торак тормышының гади бер киче иде. Кайбер студентлар ашарга пешерә, кемдер контроль эшкә әзерләнә... Көтмәгәндә-уйламаганда Казанда кар ява башлады! Көне буе укып арыган студентлар, ябалак-ябалак яуган карны күргәч, бөтен эшләрен ташлап, урамга чыга башлады. Ярты сәгать эчендә Универсиада авылының ишегалдына йөзләгән студент җыелды.

Үлкичне Универсиада авылы зур бер балалар бакчасын хәтерләтте. Студент исеме алган егет-кызлар үзләрен нәкъ сабыйлар кебек хис иткәндер, мөгаен. Кар атышып уйнау, җепшек карны тәгәрәтеп, Кар бабайлар ясау – болар һәммәсе бетмәстәкәнмәс шатлык бүләк итте безгә. Әле исемен дә сорап өлгермәгән яңа танышың белән уйнау, аның елмаеп, сиңа җавап кайтаруы, күмәк фотоларга төшү онытылмаслык, күңелле мизгелләр бүләк итте. Универсиада авылы кырмыска оясы кебек гөж килеп торды. Бик күпләр бу кичтә яңа дуслар, фикердәшләр тапты. Кар атышып уйнаудан юешләнгән киемнәрнебезне, алсуланган битләрне, тамчы-тамчы су агып торган бияләй-перчаткаларны, атакага дучар булган йорт диварларын фотосурәтләрдән карап, елмаеп искә алулары ничек күңелле булачак! Дәресләрне, вактөяк эшләрне онытып, балачакка кайтып килү һәркем өчен файдага гына булды, минемчә. Сәгать унбер тулып килсә дә, йортларга ашыгучылар сирәк иде. Күпләребез сакчылар кисәтү ясагач кына таралышты.



Марат Каримов фотосы

Бүлмәгә кергәч, тәрәзәдән урамга күз салдым: яңа яуган кар өстендә меңләгән эз. Читтәрәк карны таптап, бизәкләр ясаганнар, институтларның исемнәрен язганнар. Кар өстендә калган эзләребез иртән югалса да, күңелләрдә Универсиада авылының бу киче бүләк иткән якты хисләр, матур хатирәләр әле бик озак сакланачак һәм безне җылытып торачак.

Санаулы сәгатьләр эчендә үзебезгә-үзебез чып-чын бәйрәм ясадык без. Ә барысы да шәһәр өстенә яуган гап-гади кар бөртекләреннән башланды... Күптән сагынып көткән кар бөртекләреннән!

● Сәламәтлек

# Халык әйтсә, хак әйтә!

Киңәшләрне **Алисә ӘХӘТОВА** бирә, Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты



Һава торышының көн саен алышынуы сәламәтлегебезгә зыян салырга мөмкин. Шуңа күрә иммунитетны ныгытырга, витаминлы ризыклар кулланырга кирәк. Гриппны медицинада температураны төшерә торган, вируска каршы һәм башка препаратлар белән дәвалыйлар. Ләкин халыкның үзендә дә бу авыруны җиңеп чыгарга булыша торган дәвалану чаралары җитәрлек:

* Гриппның беренче билгеләре күренүгә, кечкенә генә суганны чистартыгыз, угычтан уыгыз һәм бинтка төрегез. Шушы компрессны борынга капларга һәм 10 минут тотарга. Бу процедураны тәүлеккә 3 мәртәбә кабатларга кирәк. Борын тиресе ялкынсынмасын өчен, һәрдаим сыек май сөртеп торыгыз.
* Салкын тигәндә, көнгә 3 мәртәбә тавык шулпасы ашарга кирәк. Бу авырган вакытта көч бирә һәм тизрәк терелергә ярдәм итә.
* Мөгаен, иң үзенчәлекле дәвалану алымын кытайлар уйлап тапкандыр. Алар фикеренчә, бернинчә энә кадау сеансы гриппны тулысынча юкка чыгара ала.
* Тамакның шешүен туктату өчен, бал белән каңферне бергә бутап, көнгә 2-3 тапкыр кулланырга киңәш итәләр.
* Әгәр томау төшсә, биш тамчы йод һәм марганецны җылы суга салып болгатырга һәм көнгә бернинчә мәртәбә борынны юарга.
* Тән температурасы югары булса, әфлисун, лимон, алма, помидор һәм чөгендер суларын кушып эчегез.
* Гриппның беренче билгеләре күренүгә, «36 массажы» ясагыз. Тынычланыгыз, әкрен генә уч төпләрегез җылынганчы уыгыз. Шуннан соң бармак белән борынның төбеннән очына кадәр 36 мәртәбә ышкыгыз. Аннары муеннан яңак сөягенә таба, колактан өстә һәм аста, баш артыннан аста, баш мие урнашкан урынга массаж ясагыз. Барысын да 36шар тапкыр кабатларга.
* Иртә белән үзеңне яхшы хис итү өчен, йокларга ятар алдыннан бер кайнар кайнар алма суы эчү киңәш ителә.
* Ангинадан котылу чарасы – керосин. Бармакка бинт урыйлар һәм керосинга чылаталар. Шуның белән тамакны сөртәләр.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Басылырга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.